**Иске Илтерәк авыл җирлеге составына керүче Чуаш Еноруcкино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

2020 ел, 29 октябрь №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Илтерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 05.11.2019 ел, 111 номерлы карары нигезендә, 2020 елның 29 октябрендә Аксубай муниципаль районының Чуаш Еноруcкино авыл җирлегендә узган халык җыены нәтиҗәләре буенча халык җыены сорау буенча беркетмә төзелде: «Аксубай муниципаль районы Чуаш Еноруcкино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән сез риза буласызмы?

**1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- вак таш капламалы поселок эчендәге юлларын чокырлы ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
-вак таш капламлы юл полотносы урнаштыру, грунт салу, юл капламын тигезләү (грейдирование), вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү, вак таш сатып алу);
- авыл эчендәге автомобиль юлларын кышкы чорда торак пунктта тоту (килешү буенча эш өчен түләү).

**2) Әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор чапкычына запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

**3) Каты коммуналь калдыкларны (ККК) җыю (шул исәптән аерым туплану) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу.**

- контейнер мәйданчыгы төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

« РИЗА » «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 280 граждан,

тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 173 граждан кертелгән.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

« РИЗА» позиция өчен 173 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены

ХӘЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Чуаш Енорускино авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Аксубай муниципаль районы Чуаш Енорускино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән **сез риза буласызмы?**

**1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- вак таш капламалы поселок эчендәге юлларын чокырлы ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-вак таш капламлы юл полотносы урнаштыру, грунт салу, юл капламын тигезләү (грейдирование), вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү, вак таш сатып алу);

- авыл эчендәге автомобиль юлларын кышкы чорда торак пунктта тоту (килешү буенча эш өчен түләү).

**2) Әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор чапкычына запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

**3) Каты коммуналь калдыкларны (ККК) җыю (шул исәптән аерым туплану) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу.**

- контейнер мәйданчыгы төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Иске Илтерәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны халыкка җиткерергә һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы: С. М. Маклаков